**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Вопросы организации тестирования государственных гражданских служащих Республики Татарстан и граждан, претендующих на замещение должностей государственной гражданской службы Республики Татарстан**

В целях совершенствования деятельности государственных органов Республики Татарстан по оценке уровня профессиональных знаний и навыков государственных гражданских служащих Республики Татарстан и граждан, претендующих на замещение должностей государственной гражданской службы Республики Татарстан, **постановляю:**

1. Установить, что при проведении в исполнительных органах государственной власти Республики Татарстан тестирования государственных гражданских служащих Республики Татарстан и граждан, претендующих на замещение должностей государственной гражданской службы Республики Татарстан, оценка уровня профессиональных знаний и навыков осуществляется в соответствии с методикой тестирования, утверждаемой Департаментом государственной службы и кадров при Президенте Республики Татарстан.

2. Департаменту государственной службы и кадров при Президенте Республики Татарстан:

в 30-дневный срок разработать и утвердить методику тестирования государственных гражданских служащих Республики Татарстан и граждан, претендующих на замещение должностей государственной гражданской службы Республики Татарстан (далее – методика тестирования);

организовать работу по практическому применению методики тестирования в государственных органах Республики Татарстан.

3. Руководителям исполнительных органов государственной власти Республики Татарстан обеспечить применение методики тестирования.

4. Предложить руководителям государственных органов Республики Татарстан, не являющихся исполнительными органами государственной власти Республики Татарстан, обеспечить применение методики тестирования.

5. Контроль за исполнением настоящего Указа возложить на Руководителя Аппарата Президента Республики Татарстан.

6. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань,Кремль
11 декабря 2015 года
№ УП-1192

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарга тест уздыруны оештыру мәсьәләләре**

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның һөнәри белемнәре һәм күнекмәләре дәрәҗәсен бәяләү буенча Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеген камилләштерү максатларында **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарга тест уздырган вакытта һөнәри белем һәм күнекмәләр дәрәҗәсен бәяләү Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан расланачак торган тест уздыру методикасы нигезендә башкарыла дип билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментына:

30 көн эчендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарга тест уздыру методикасын эшләргә һәм расларга (алга таба – методика);

Татарстан Республикасы дәүләт органнарында тест уздыру методикасын гамәлдә файдалану буенча эшне оештырырга.

3. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары җитәкчеләренә тест уздыру методикасын файдалануны тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары булмаган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары җитәкчеләренә тест уздыру методикасын файдаланырга тәкъдим итәргә.

5. Әлеге Указның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесенә йөкләргә.

6. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2015 ел, 11 декабрь
№ ПУ-1192